# ТАМЫР ҺӘМ КУШЫМЧА

**И сабыйлар!**

**Эшләгез сез,**

**Иң *мөкатдәс* нәрсә –**

**эш!**

Шигырьдә сүз нәрсә турында бара?
Шигырьне кем язган?
Бу юллар аның кайсы шигыреннән?
Сез әти-әниләрегезгә булышасызмы соң?
Мөкатдәс дигән сүзне сез ничек аңлыйсыз?

# Үткәннәрне кабатлау

**Без уй-фикерләребезне нәрсәләр ярдәмендә белдерәбез?**

**Җөмләләр нәрсәләрдән төзелә?**

**Сүзләр нәрсәләрдән тора?**

# Нәрсәләрнең тамырлары була?










# Эш агачы




эшмәкәр
эшләнеш
эшлекле
эшчәнлек
эшчән
эшлә
эшче
эшле
Эш

# Тамырга ялганып килә торган кисәкләр ничек атала?

Калын әйтелешле сүзләргә һәрвакыт нинди кушымчалар ялгана?

Нечкә әйтелешле сүзләргә нинди кушымчалар ялгана?

Бакчачы, авылдаш, юлчы, балалар, мэктэптэ, кошларны.

# Тест

| Сораулар | Әйе (+) | Юк (-) |
|---|---|---|
| **Җөмлә сүзләрдән төзелә.** | | |
| **Бер тамырдан ясалган сүзләр тамырдаш сүзләр дип атала.** | | |
| **Сүз авазлардан тора.** | | |
| **Сүзнең төп мәгънәсен аңлата һәм мәгънәле башка кисәкләргә бүленми торган кисәге тамыр дип атала.** | | |
| **Иҗек хәрефләрдән төзелә.** | | |
| **Иң кечкенә иҗек бер аваздан гына тора.** | | |
| **Калын әйтелешле сүзгә һәрвакыт нечкә кушымча ялгана.** | | |
| **Тамырга ялганып килә торган кисәкләрне кушымчалар диләр.** | | |
| **Нечкә әйтелешле сүзләргә калын кушымча ялгана.** | | |
| ***Балачак* сүзенең тамыры *бала*, кушымчасы *чак*** | | |
| ***Көлмәк* сүзенең тамыры *көл*, кушымчасы *мәк*** | | |

# Өй эше

51 биттәге рәсемнәр буенча “Зоопаркта”, “Урманда” дигән темага кечкенә хикәя яз.